МУНИЦИПАЛЬНОЕ АВТОНОМНОЕ ДОШКОЛЬНОЕ
ОБРАЗОВАТЕЛЬНОЕ УЧРЕЖДЕНИЕ

**«ЗАБАВА»**

Детский сад комбинированного вида «106»
г. Набережные Челны

Раслыйм:
«Кызыклы уен» 106 нчы балалар бакчасы»
МАМББ житәкчесе ________
Гимадеева З.Д.
«26» 08 ________

Каралды һәм кабул ителде
педагогик советта
«26» 08 ________
беркетмә № 1

# «Кызыклы уен» 106 нчы катнаш балалар бакчасы» муниципаль автономияле мәктәпкәчә белем бирү учреждениесе 1 нче санлы кечкенәләр (2-3 яшь) төркеменең 2022-2023 нче уку елына эш программасы.

Төзүче тәрбияче:
Мухаметдинова Лилия Шамил кызы

**Яр Чаллы шәһәре**
**2022 ел**

# Эчтәлек


| | | |
|---|---|---|
| **1** | **Максатлар бүлеге** | 3 |
| 1.1 | Аңлатма язуы. | 3 |
| 1.2 | Программаны гамәлгә ашыруның максатлары һәм бурычлары. | 3 |
| 1.3. | Программаны формалаштыру принциплары һәм юллары. | 4 |
| 1.4. | 2-3 яшлек балаларныңпсихик үсешенең яшь үзенчәлекләре. | 6 |
| 1.5. | Программаны үзләштерүнең планлаштырылган нәтиҗәләре. | 7 |
| **2** | **Эчтәлек бүлеге** | 7 |
| 2.1 | Комплекслы – тематик планлаштыру | 8 |
| 2.2 | Белем бирү өлкәләре | 50 |
| 2.2.1. | «Физик үсеш» белем бирү өлкәсе | 50 |
| 2.2.2 | «Социаль-коммуникатив үсеш» белем бирү өлкәсе | 52 |
| 2.2.3. | «Танып белү үсеше» белем бирү өлкәсе | 53 |
| 2.2.4. | «Сәнгати-эстетик үсеш»белем бирү өлкәсе. | 55 |
| 2.2.5 | «Сөйләм үсеше» белем бирү өлкәсе. | 56 |
| 2.3 | Ата-аналар белән эш планы | 58 |
| **3** | **Оештыру бүлеге** | 59 |
| 3.1 | Программаның матди-техник тәэмин ителеше. | 59 |
| 3.2 | Программа методик тәэмин итү | 59 |
| 3.3 | Предметлы тирәлек мохитны үстерү | 59 |
| 3.4 | Балаларның көн тәртибе үрнәге | 63 |
| 3.5 | Белем бирү эшчәнлеге челтәре. | 64 |
| 3.6 | Фәнни әдәбият | 65 |
| | | |

## 1.1АҢЛАТМА ЯЗУЫ

Без тирән үзгәрешләр һәм икътисади үзгәртеп корулар чорында яшибез. Белем бирүнең беренче баскычы булган мәктәпкәчә тәрбия учреждениеләренең эше дә көннән-көн яңара, матур традицияләргә байый.Педагоглар яшь буынны тәрбияләүдә яңа чаралар, беләм бирүнең нәтиҗәле методларын эзлиләр, тәрбия эшендә халкыбызның күркәм традицияләренә, педагогик тәҗрибәсенә ныграк таяналар. Балаларның физик, интеллектуаль һәм шәхси үсешен тәэмин итү, иҗат мөмкинлекләрен ачу һәм үстерүгә зур игътибар бирелә.

Федераль дәүләт таләпләреннән чыгып төзелгән программабыз Н.Е. Веракса, Т.С. Комарова, И.А. Васильева редакциясендә чыккан “Туганнан алып мәктәпкә кадәр. Мәктәпкәчә мәгарифнең якынча төп белем бирү программасы”, Татарстан Республикасы Мәгариф министрлыгы тарафыннан расланган “Балалар бакчасында тәрбия белем бирү программасы” (төзүчеләрәре: К.В. Закирова, Р.А. Борһанова) нигезендә төзелде.Әлеге әсбап танып белү, коммуникация, матур әдәбият уку кебек өч белем бирү өлкәсен үз эченә ала. Балаларның белем бирү өлкәләре эчтәлеген ни дәрәҗәдә үзләштерүләрен ачыклау максатыннан диагностик методикалар бирелә. Методик әсбап мәктәпкәчә белем бирү учреждениесе хезмәткәрләренә, урта, югары һөнәри белем алучы студентларга, мәктәпкәчә белем бирү сферасында эшләгән мөгаллимнәргә, әти-әниләргә тәкъдим ителә.

**Программа түбәндәге бурычларны куя:**

- Балаларның сәламәтлеген саклау, аларның физик һәм психик үсешен тәэмин итү;
- Тәрбия-белем бирү эшен гуманлаштыру;
- Халык традицияләренә, милли гореф гадәтләргә нигезләнеп балаларда әхлакый сыйфатлар тәрбияләү;
- Балаларның сәләтләрен ачу, юнәлеш бирү һәм үстерү өчен шартлар тудырып, нык белемле, зирәк акыллы шәхес формалаштыру;
- Балалар иҗаты нәтиҗәләренә хөрмәт белән карау;
- Балалар бакчасы һәм башлангыч мәктәп эшендә дәвамчанлыкны саклау.

Программаның психик-педагогик эшнең эчтәлеге төп биш өлкәгә бүленгән:

1. «Физик үсеш»
2. «Сөйләм үсеше»
3. «Социаль – коммуникатив үсеш»
4. «Танып-белү үсеше»
5. «Нәфис-нәфасәти үсеш»

Бу бурыч-максатларны тормышка ашыру һәр тәрбиячеынең педагогик осталыгыннан аның мәдәниятлелегеннән, әхлаклылыгыннан, максатчан эшләвеннән һәм иң мөһиме балаларны яратуыннан тора. Тәрбияче балаларның сәламәтлеген, тәрбиялелеген, әхлаклылыгын кайгыртып әти-әниләр белән берлектә һәр баланы бәхетле итәргә тиеш.

### 1.2 Программаны гамәлгә ашыруның максатлары һәм бурычлары.

(2-3 яшьлек балаларның тәрбия бурычлары).

Балаларның сәламәтлекләрен ныгыту һәм саклау эшен дәвам итү. Бала организмын аими чыныктыру өчен шартлартудыру. Шөгыльләрдә, көндәлек эшчәнлектә төп хәрәкәт төрләрен башкару осталыкларын һәм күнекмәләрен формалаштыру. Гәүдәне төз тотарга өйрәтү, чисталык күнекмәләренкамилләштерү. Балаларның әйләнә-тирәдә ориентлаша белүләрен үстерү. Күмәк уеннарда һәм физик күнегүләрдә катнашуга дәртләндерү. Актив хәрәкәт эшчәнлеге, уңай эмоцияләр тудыруга булышлык итү.

Өлкәннәрнең һәм яшьтәшләренең тормышы һәм эшчәнлеге, табигать күренешләре белән кызыксыну тәрбияләү. Предметлар һәм күренешләр арасындагы бәйләнешләрне аңларга һәм шуның аша гади генә нәтиҗәләр чыгара белергә өйрәтү. Балаларның сөйләмен үстерүне дәвам итү: сүзлек запасын баету, җөмләләр төзи белү, сүзләрне дөрес һәм ачык итеп әйтүләренә ирешү.

Әдәби әсәрне ахыргача тыңлый, экияттә, хикәядә вакыйгаларның ничек үрелеп баруын күзәтә белү сыйфаты тәрбияләү; өлкәннәр ярдәмендә кечкенә шигырьләрне, юаткычларны укырга һәм хәтерләрендә калдырырга ярдәм итү.

Гади математик күзаллаулар формалаштыру. Тирә-юньдә бер һәм күп санлы редметларны табарга, предмет төркемнәрен чагыштырырга, кайсы предметларның күбрәк икәнен билгеләргә өйрәтү.

Өлкәннәр хезмәтенә уңай мөнәсәбәт формалаштыру. Көченнән килгән кадәр хезмәткә катнашу теләге уяту, кечерәк кыенлыкларны җиңә белергә өйрәтү.

Балалар бакчасында, өйдә, урамда бердәм тәртип күнекмәләрен ныгыту. Нәрсә яхшы һәм нәрсә начар булуы турында иң гади күзаллаулар формалаштыруны дәвам итү. Балаларда дустанә мөнәсәбәт, кешелеклелек, шәфкатьлелек тәрбияләү өчен шартлар тудыру. *Мин* образын тәрбияләү, үстерү.

Балаларның Музыкаль сәләтләрен үстерү; музыка, Музыкаль әсәрләр тыңлый һәм музыка яңгырашындагы үзгәрешләрне тоя белергә, матур итеп җырларга һәм музыка астында ритмлы хәрәкәтләр ясарга өйрәтү.

Балаларның нәфасәти хисләрен, сәнгати зиһенгә алу сәләтен үстерү; әдәби һәм Музыкаль әсәрләргә, әйләнә-тирә дөньяның, сәнгать әсәрләренең матурлыгына тойгы-кичерешле мөнәсәбәт булдыру.

Балаларда әйләнә-тирәнең матурлыгына, сәнгать әсәрләренәэстетик караш тәрбияләү. Әвәләүдә, аппликация, рәсемдәпредметларның һәм чынбарлыктагы күренешләрнең гади образларын бирергә өйрәтү.

Балаларны төрле уеннар белән кызыксындыру. Уен өченкүңелләренә ошаган 2—3 бала белән төркемнәр оештырыргаярдәм итү. Уен барышында гади кагыйдәләрне үтәү зарурлыгын төшендерү. Уенчыклар, төзелеш һәм табигать материаллары белән оештырылган уеннар ярдәмендә балаларныңтирә-юнь турындагы белемнәрен киңәйтү, кызыксынуларынүстерү.

## 1.3.Программаны формалаштыру принциплары һәм юллары

Программада белем бирүнең бала шәхесен формалаштыруны тәэмин итүче һәм педагогны аның индивидуаль үзенчәлекләренә юнәлтүче үстерү функциясе беренче планга чыга, бу балачакның мәктәпкәчә чорының үзкыйммәтен тану турындагы хәзерге фәнни «Мәктәпкәчә тәрбия концепциясе»нә (авторлары В.В. Давыдов, В.А. Петровский һ.б.) туры килә.

Программа балага карата гуманлылык һәм шәхес итеп карау мөнәсәбәтләрендә төзелгән һәм аның һәрьяклы үсешенә, рухи һәм гомумкешелек кыйммәтләрен, шулай ук сәләтләрен һәм интегратив сыйфатларын формалаштыруга юнәлтелгән.

Программада балаларның белемен катгый регламентацияләү һәм укытуда предметлы үзәкләштерү юк.

Программаны эшләгән вакытта авторлар мәктәпкәчә белем бирүнең илкүләм иң яхшы традицияләренә, аның фундаментальлегенә: балаларның тормышын саклау һәм сәламәтлеген ныгыту буенча бурычларны комплекслы хәл итүгә; һәрьяклы тәрбиягә; балалар иҗат эшчәнлегенең төрле төрләрен оештыру нигезендә үсешне баетуга (амплификацияләү) таяндылар.

Программада мәктәпкәчә яшьтәге балалар өчен төп әһәмияткә ия уен эшчәнлегенә аерым урын бирелә (А.Н. Леонтьев, А.В. Запорожец, Д.Б. Эльконин һ.б.).

Программа авторлары аеруча мөһим дидактик принципны — үсешкә китерүче укытуны һәм Л.С. Выготскийның дөрес оештырылган укыту үз артыннан үсешне «ияртә» дигән фәнни нигезләмәсен исәпкә алып эш иттеләр. Тәрбия һәм психик үсеш икесе аерым, бер-берсе белән бәйләнмәгән процесс буларак карала алмыйлар, әмма бу очракта «тәрбия бала үсешенең кирәкле һәм гомумкүләм формасы сыйфатында хезмәт итә» (В.В.Давыдов). Шулай итеп, Программа кысаларында үсеш балаларга тәрбия һәм белем бирүдә уңышлылыкның иң мөһим нәтиҗәсе булып тора.

Программада баланы туганнан алып мәктәпкәчә тәрбияләүнең һәм аңа белем бирүнең барлык төп эчтәлек юнәлешләре комплекслы күрсәтелә.

Программа мәдәни ярашканлык принцибына корылган. Әлеге принципны гамәлгә ашыру белем бирүдә милли кыйммәтләрне һәм традицияләрне исәпкә алуны тәэмин итә, рухи-әхлакый һәм эмоциональ тәрбия бирүдәге җитешсезлекләрдән арынырга булыша. Белем бирү баланы кешелек мәдәниятенең төп компонентларына (белем, әхлак, сәнгать, хезмәт) якынайту процессы буларак карала.

Программа материалын сайлауның төп критерие — аның тәрбияви кыйммәте, кулланылган мәдәният әсәрләренең (илебез, шулай ук чит илләр классикасы һәм халык иҗаты) югары сәнгатьлелек дәрәҗәсе, мәктәпкәчә балачакның һәрбер этабында баланың һәрьяклы сәләтләрен үстерү мөмкинлеге (Е.А. Флерина, Н.П. Сакулина, Н.А. Ветлугина, Н.С. Карпинская).

«Туганнан алып мәктәпкәчә» программасы:

- баланың үсешенә ирешүне максат итеп куйган үсешкә китерүче белем бирү принцибына туры килә;
- фәнни нигезләнгәнлек һәм гамәлдә кулланучанлык принципларын исәпкә ала (Программаның эчтәлеге яшь чорлары психологиясе һәм мәктәпкәчә педагогиканың төп нигезләмәләренә туры килә һәм, тәҗрибәләр күрсәткәнчә, массакүләм мәктәпкәчә белем бирү практикасында уңышлы гамәлгә ашырыла ала);
- тулылык, зарурлык һәм җитешлелек критерийларына туры килә (җитәрлек күләмдә «минимум» материал кулланганда, куйган максатлар һәм бурычларны хәл итәргә мөмкинлек биреп);
- мәктәпкәчә яшьтәге балаларга белем бирү процессының тәрбияви, үсеш һәм укыту максатлары һәм бурычлары бергәлеген тәэмин итә, аларны гамәлгә ашыру барышында мәктәпкәчә яшьтәге балалар үсешенең нигезен тәшкил итүче сыйфатлар формалаша;
- балаларның яшь мөмкинлекләренә һәм үзенчәлекләренә, белем бирү өлкәләренең үзенчәлегенә һәм мөмкинлекләренә туры китереп, белем бирү өлкәләренең интеграциясе принцибын исәпкә алып төзелә;
- белем бирү процессын коруның комплекслы-тематик принцибына нигезләнә;
- программалы белем бирү бурычларын өлкәннәр һәм балаларның уртак эшчәнлегендә һәм мәктәпкәчә яшьтәге балаларның мөстәкыйль эшчәнлегендә хәл итүне турыдан-туры белем бирү эшчәнлеге кысаларында гына түгел, мәктәпкәчә белем бирүнең үзенчәлегенә туры китереп, режим моментларын уздырган вакытта да күздә тота;
- белем бирү процессын балалар белән эшләүнең яшь үзенчәлекләренә туры килгән формаларын куллану аша оештыруны күздә тота. Мәктәпкәчә яшьтәге балалар белән эшләүнең төп формасы һәм алар эшчәнлегенең әйдәп баручы төре булып уен исәпләнә;
- төбәк үзенчәлекләренә бәйле рәвештә белем бирү процессын төрләләндерүгә юл куя;
- мәктәпкәчә яшьтәге барлык төркемнәр арасында һәм балалар бакчасы белән мәктәп арасында дәвамчанлыкны саклауны исәпкә алып төзелә.

## 1.4 БАЛАЛАРНЫҢ ЯШЬ ҮЗЕНЧӘЛЕКЛӘР:

2-3 яшьлек баланың карашлары акрынлап гаилә чикләрен үтеп чыга башлый. Ситуацияләрдән тыш аралашулар барлыкка килә. Олы кеше аның өчен гаилә әгъзасы гына түгел, ә аерым иҗтимагый функция башкаручыга да әйләнә. Баланың да

иҗтимагый функция башкарасы килү теләге аның реаль мөмкинлекләре белен каршылыкка китерә. Бу каршылык мәктәпкәчә яшьтәгеләр эшчәнлегенең төп төре булган уен ашачишелә.

Шартлылык уенның теп үзенчәлеге булып тора: бер төрлепредметлар белән эш-хәрәкәтләр аларның башка предметларбелән икенче эш-хәрәкәтләргә каравын күз алдында тота.Уенчыклар һәм аларны алмаштыручы предметлар белән эшгамәлләр кече яшьтәге балалар уенының теп эчтәлеген тәшкилитә. Кече яшьтәгеләр 1—2 рольле яки гади, җыйнак сюжетлыуеннар белән канәгатьләнәләр. Бу яшьтә кагыйдәле уеннар формалаша гына башлый эле.

Баланың сурәтләү эшчәнлеге аның предмет турында күзаллауларына бәйле. Бу яшьтә ул эле формалаша гына. Графикобразлар бик гади, ярлы. Кайбер балаларның сурәтләрендәдетальләр җитешми, башкаларның рәсемнәре беркадәр детальләштерелгән булырга мөмкин. Балалар инде тәсләрне кулланабеләләр.

Кул чуклары хәрәкәтен үстерүдә әвәләүнең әһәмияте гаятьзур. Кече яшьтәгеләр олылар җитәкчелегендә әвәләп гадипредметлар ясарга сәләтле.

Белүебезчә, кисеп ябыштыру кабул итүчәнлекне (зиһенгәалуны) үстерүгә уңай йогынты ясый. Бу яшьтә балалар аппликациянең иң гади тәрләрен эшли алалар.

Кече яшьтәгеләр өчен конструкцияләү эшчәнлеге күрсәтелгән үрнәк буенча һәм үзләре уйлап тапкан гади корылмалартөзүдән гыйбарәт.

Кече мәктәпкәчә яшьтә перцептив эшчәнлек үсеш ала.Балалар зиһенгә алуның шәхси берәмлекләреннән сенсорикэталоннарга — белем һәм күнекмәләр ярдәмендә барлыкка килгән зиһенгә алу чараларын куллануга күчәләр.

Кече мәктәпкәчә яшьнең ахырына балалар 5 тан артык предмет формаларын һәм 7 дан артык төсне кабул итәргә,предметларны зурлыклары буенча аерырга, төркем эчендә, эшчәнлекне дөрес оештырганда, балалар бакчасы бинасындада ориентлашырга сәләтлеләр.

Аларның хәтере һәм игътибарлылыгы үсә. Олылар тәкъдиме белән балалар 3—4 сүз һәм 5—6 предмет исемен истакалдыралар. Кече мәктәпкәчә яшьнең ахырына алар яратканәсәрләреннән өзекләрне иста калдырырга сәләтле.

Күрсәтмәле-тәэсирле фикер йөртү салате үсеше дәвам итә.Шуның белән бергә, ситуацияләр кайбер очракларда уңай нәтиҗәне күздә тоткан максатчан сынаулар нигезендә үзгәртелә. Балалар предметлар арасындагы кайбер яшерен мөнәсәбәтләрне ача алалар.

Бу яшьтә иҗади күзаллау салате үсә башлый. Балалар уен вакытында бер төрле объектларны башкаларын алыштыручылар сыйфатында кулланалар.

Балалар арасындагы мөнәсәбәтләр аерым нормаларга һәмкагыйдәләргә буйсындырыла. Максатчан йогынты нәтиҗәсендәалар башка балаларның һәм үз эшгамәлләрен бяли белүгәнигез булган күп кенә нормаларны үзләштерә алалар.

Балалар арасындагы мөнәсәбәтләр бигрәк та уен эшчәнлегендә ачык чагыла. Алар күбрәк бергәләшеп түгел, а янәшәуйнауны өстен күрәләр. Ләкин инде бу яшьтә балалар арасындасайлап алуга корылган мөнәсәбәтләр өстенлек итә. Низагларкүбесенчә уенчыклар аркасында килеп чыга. Баланың төркемдә яшьтәшләре арасындагы дәрәҗәсе нигездә тәрбиячефикере белән билгеләнә.

Бу яшьтә балалар аңлы рәвештә үз тәртипләре белән идарәитә белмиләр, күбесенчә баланың тәртибе ситуациягә бәйле.Шуның белән беррәттән, балаларның, олылар әйтүе буенча,нindидер теләкләрен чикләү очраклары да күзәтелә. Үз-үзенбәяләү сыйфаты үсә башлый, бу күп очракта тәрбияче фикеренәнигезләнгән була. Җенси аерымлыкларның да үсеше күзәтелә.Ул бигрәк та уенчыклар һәм уен сюжетларын сайлаганда(кызлар —

курчак, малайлар машина сайлый) ачык чагыла.

### 1.5 ПРОГРАММАНЫ ҮЗЛЕШТЕРҮНЕҢ ПЛАНЛАШТЫРЫЛГАН НӘТИҖӘЛӘРЕ

Төбәкнең мәктәпкәчә белем бирү программасы баланыңһәрьяклы (физик, социаль-коммуникотив, танып белү, сөйләм, нәфис-нәфасәти) үсешенә юнәлдерелә һәм баланың үсешен миллимәдәнният башлангычларына якынайту, тугаи якны һәм татар (рус) телен өйрәнү ярдәмендә баетуны күздә тота.

| Вакыты | Тема | Бурычлар | Әдәбият |
|---|---|---|---|

Балаларның планлаштырылган нәтиҗәләргә ирепгүе буенча мониторинг системасы арадаш нәтиҗәләрне һәм Программаны үзләштерүнең йомгаклау нәтиҗөләрен бәяләүне күздәтота.

Программа үзләштерүнең планлаштырылган йомгаклау нәтиҗәләре мәктәпкәчә мәгарифнең төп гомуми белем бирү программасьш үзләштергән 7 яшьлек баланың социаль портреты рәвешендә психолого-педагогик эшнең максатларын җентекләп тасвирлый. Алар мәктәпкәчә мәгарифнең төп гомуми белембирү программасын эшләү һәм планлаштыру, шулай ук аны тормышка ашыру барышында куелган көчнец юнәлешенкүрсәтәләр.

Мәктәпкәчө белем бирү учреждениесенең чыгарылыш баласы портреты гаиләнең, җәмгыять һәм дәүләтнең мәктәпкәчәяшьтәге балаларның белем бирү өлкәсендәге кызыксынуларын һәм ихтыяҗларын чагылдыра. 7 яшьлек баланың социальпортретын аның интегратив сыйфатлары тәшкил итә.

*Шәхси сыйфатлар* тәрбияләнүченең шәхси сферасыүсешен (ихтыяр, хис, үз-үзеңә бәя бирү, иреклелек, мотивация), шулай ук әхлакый үсешен чагылдыра.

*Физик сыйфатлар* тәрбияләнүченең физик үсешен (көч, түземлек, гәүдә сыгьшмалылыгы, координация, җитезлек, тизлек) күрсәтә.

*Интеллектуаль сыйфатлар* баланың интеллектуаль сферасы үсешен (югары психик функцияләр формалашуны, социаль тәҗрибә туплауны)

# 2 Эчтәлекле бүлек

## 2.1Комплекслы- тематик план

**Танып белү (әйләнә-тирә белән танышу)**

| | | | |
|---|---|---|---|
| Сентябрь<br>1нче атна | Чишенү<br>бүлмәсен карау | 1 Балаларны чишенү бүлмәсе, андагы җиһазлар белән таныштыру, төркемдәге (группадагы) бүлмәләрдә ориентлашу тәҗрибәсе туплау; 2) балаларның кабул итү сәләтен, игътибарын, диалогта катнашу теләген үстерү; 3) җиһазларга сакчыл караш тәрбияләү. | “Туган телдә сөйләшәбез “Ф. В. Хәзрәтова, З. Г. Шәрәфетдинова, И. Ж. Хәбибуллина<br>32 б. |
| Сентябрь<br>2нче атна | Юыну<br>бүлмәсен карау | 1) Балаларны юыну бүлмәсендәге предметлар (сабын, сөлге, кран, су, теш щёткасы, теш пастасы) белән таныштыру, функциональ билгеләнешләре турындагы күзаллауларын ачыклау; 2) сүзләрне төрле грамматик формаларда (сабын, сабынны, сабын белән һ.б.) куллану осталыгына ирешү, балаларның сөйләм активлыгын, инициативасын үстерү; 3) балаларны сөйләм этикетының гади формаларын (исәнл әшү, саубуллашу) кулланырга гадәтләндерү, пөхтәлек, чисталык, башкаларга ярдәм итү омтылышы тәрбияләү. | “Туган телдә сөйләшәбез “Ф. В. Хәзрәтова, З. Г. Шәрәфетдинова, И. Ж. Хәбибуллина<br>39 б. |
| Сентябрь<br>3нче атна | “Көзге<br>табигаттә<br>кунакта” | 1) Балаларның көз (табигатьтәге үзгәрешләр, кешеләрнең киеме һ.б.) турында гади күзаллауларын формалаштыру; 2) балаларның күзәтүчәнлеген, игътибарын, тәрбиячене тыңлый белү осталыгын үстерү; 3) көзге табигатькә соклану хисләре тәрбияләү. | “Туган телдә сөйләшәбез “Ф. В. Хәзрәтова, З. Г. Шәрәфетдинова, И. Ж. Хәбибуллина<br>41 б. |
| Сентябрь<br>4нче атна | Яшелчәләр:<br>помидор, кыяр,<br>кишер белән<br>таныштыру | 1 Балаларның помидор, кыяр, кишер турындагы белемнәрен ныгыту; помидор, кыяр, кишернең форма, төс, тәм үзенчәлекләре (кызыл, йомшак, шома, тәмле, сусыл, шар формасындагы помидор; яшел, каты, шома, кытыршы кыяр; шома, кызыл, тәмле, каты кишер) белән таныштыру; 2) балаларның сенсор тою сәләтен, тәрбиячене ишетү һәм сорауларга җавап бирү осталыгын үстерү; 3) балаларны сөйләм этикетының гади формаларын (исәнләшү, саубуллашу) кулланырга гадәтләндерү, зурлар хезмәтенә хөрмәт тәрбияләү. | “Туган телдә сөйләшәбез “Ф. В. Хәзрәтова, З. Г. Шәрәфетдинова, И. Ж. Хәбибуллина<br>47 б. |
| Октябрь<br>1нче атна | “Җиләк-<br>җимешләр” | 1) Тышкы билгеләре һәм тәме буенча җиләк-җимешләрне аерырга өйрәтү, җиләк-җимешләр һәм аларның уңышын җыеп алу турын да күзаллауларын киңәйтү, җиләк-җимешләрнең исемнәре һәм аларн ың билгеләрен белдерә торган сүзләр | “Туган телдә сөйләшәбез “Ф. В. Хәзрәтова, З. Г. Шәрәфетдинова, И. Ж. Хәбибуллина<br>47 б. |

| | | | |
|---|---|---|---|
| | | хисабына балаларның сүз байлыгын үстерү; 2) балаларның игътибарын, кабул итү һәм сенсор тою сәләтен, сорауларга җавап бирү осталыгын үстерү; 3) балаларны сөйләм этикетының гади формаларын (исәнләшү, саубуллашу) куллана белергә гадәтләндерү, әйләнә-тирә табигать объектларына | |
| Октябрь 2нче атна | Уенчыклар "Йомшаккай бездә кунакта" | 1. Балаларның уенчыклар турындагы белемнәрен киңәйтү, тәрбияче сорауларына җавап бирү осталыгын формалаштыру, уенчык исемнәрен һәм аларның эш-хәрәкәтен белдерә торган сүзләр хисабына сүз байлыгын арттыру; 2) тыңлау һәм сорауларга җавап бирү теләген үстерү; 3) сөйләм этикетының гади формаларын (исәнләшү, саубуллашу) кулланырга гадәтләндерү, уенчыкларга сакчыл караш тәрбияләү. | "Туган телдә сөйләшәбез "Ф. В. Хәзрәтова, З. Г. Шәрәфетдинова, И. Җ. Хәбибуллина 33 б. |
| Октябрь 3нче атна | "Йомшаккай тагын бездә кунакта" | 1) Уенчыкларны карарга һәм аларның аерым өлешл әрен билгеләргә өйрәтү, уенчыкларның исемнәрен, өлешләрен әйтү; төсен, хәрәкәтен белдерә торган сүзләрне актив сүзлеккә кертү; 2) тәрбияче соравына кычкырып җавап бирү осталыгын үстерү; 3) сөйләм этикетының гади формаларын (исәнләшү, саубуллашу) кулланырга гадәтләндерү, кызыклы уенчыклар белән уйнаудан тәм табу, шатлык хисләре тәрбияләү. | "Туган телдә сөйләшәбез "Ф. В. Хәзрәтова, З. Г. Шәрәфетдинова, И. Җ. Хәбибуллина 34 б. |
| Октябрь 4нче атна | "Минем исемем бар" | 1) Баланы үзенең һәм иптәшләренең исемен әйтергә өйрәтү, исем нәрне истә калдырырга, оялчанлыкны җиңәргә ярдәм итү; 2) тәрбияче әйткәнне ишетергә һәм аңларга, кайбер фразаларны (Минем исемем — Алсу) кабатларга күнектерү; балаларның хәтерен, игътибарын үстерү; 3) балаларда зурларга һәм яшьтәшләренә карата ягымлылык, дустанә мөнәсәбәт тәрбияләү. | "Туган телдә сөйләшәбез "Ф. В. Хәзрәтова, З. Г. Шәрәфетдинова, И. Җ. Хәбибуллина 53 б. |
| Октябрь 5нче атна | "Безнең урам" | 1) Балаларны урам, андагы объектлар, күренешләр белән таныштыру, аларга карата кызыксыну тудыру; 2) балаларның күзәтүчәнлеген, игътибарын, сүз байлыгын үстерү; 3) урамга соклану хисе тәрбияләү. | "Туган телдә сөйләшәбез "Ф. В. Хәзрәтова, З. Г. Шәрәфетдинова, И. Җ. Хәбибуллина 53 б. Интернет челтәреннән |

| | | | |
|---|---|---|---|
| Ноябрь 1 нче атна | Транспорт | 1)Балаларны транспорт төрләрен таный белергә, исемнәрен әйтергә өйрәтү. 2)Балаларда күзаллау сәләтен үстерү. 3)Транспортта барганда кычкырып сөйләшергә ярамаганлыгын аңлату. | |
| Ноябрь 2 нче атна | Йорт хайваннары. | 1) Балаларның йорт хайваннары (сыер, ат, песи, эт) турындагы белемнәрен (кайда яшиләр, нәрсә ашыйлар) киңәйтү, хайваннарның исемнәрен, хәрәкәтләрен әйтергә күнектерү; 2) сүзлекне баету, тәрбияченең сорауларына җавап бирү, мөстәкыйльлек һәм активлык күрсәтү теләген үстерү; 3) йорт хайваннарына карата кызыксыну тәрбияләү | “Туган телдә сөйләшәбез “Ф. В. Хәзрәтова, З. Г. Шәрәфетдинова, И. Җ. Хәбибуллина 91 б. |
| Ноябрь 3 нче атна | Йорт кошлары | 1) Балаларны рәсемне карарга, эчтәлеге буенча сорауларга җавап бирергә, тәрбияче һәм иптәшләренең сөйләгәннәрен тыңларга өйрәтүне дәвам итү; 2) сөйләмне томшык, тавык, чебиләр, табак кебек сүзләр хисабына баету, игътибарны, хәтерне, образлы фикерләүне үстерү; 3) йорт кошларына карата мәрхәмәтлелек тәрбияләү. | “Туган телдә сөйләшәбез “Ф. В. Хәзрәтова, З. Г. Шәрәфетдинова, И. Җ. Хәбибуллина 92 б. |
| Ноябрь 4 нче атна | Халык иҗаты “Матрешкалар” | 1) Балаларны халык иҗат иткән уенчыклар (матрёшкалар) белән таныштыруны дәвам итү; матрёшканы ачарга һәм дөрес итеп җыярга өйрәтү, сүз байлыгын киңәйтү һәм активлаштыру, балаларны үзләренә әйтелгән (мөрәҗәгать ителгән) сүзләрне тыңларга күнектерү; 2) игътибарны, хәтерне, сенсор тою сәләтен, сорауларга җавап бирү осталыгын үстерү; 3) уенчыкларга сакчыллык, халык иҗатына кызыксыну тәрбияләү. | “Туган телдә сөйләшәбез “Ф. В. Хәзрәтова, З. Г. Шәрәфетдинова, И. Җ. Хәбибуллина 80 б. |
| Декабрь 1 нче атна | “Ап –ак кар ява” | 1) Балаларның кыш турында күзаллауларын киңәйтү; кар, аның билгеләре белән таныштыруны дәвам итү; балаларның кар бөртекләре турында күзаллауларын формалаштыру; табигать матурлыгына соклана белү хисләре тәрбияләү. | “Туган телдә сөйләшәбез “Ф. В. Хәзрәтова, З. Г. Шәрәфетдинова, И. Җ. Хәбибуллина 61 б. |
| Декабрь 2 нче атна | “Кыш” | 1) балаларның кыш турында күзаллауларын киңәйтү; кар, аның билгеләре белән таныштыруны дәвам итү; сөйләмдә сыйфатларны дөрес куллана белүләренә ирешү; 2) | “Туган телдә сөйләшәбез “Ф. В. Хәзрәтова, З. Г. Шәрәфетдинова, И. Җ. Хәбибуллина 89 |

| | | | |
|---|---|---|---|
| | | балаларның игътибарын, диалогик сөйләмен, рәсем ясауга кызыксынуларын, пространствода ориент лашуларын, сөйләм сулышын үстерү; 3) башкаларга ярдәм итү теләге тәрбияләү. | б. |
| Декабрь 3 нче атна | “Яшел чыршы” | 1) Балалар белән чыршыны бергәләп карау, Яңа ел бәйрәме турындагы күзаллауларын киңәйтү һәм баету;<br>2) балаларның «Яңа ел бәйрәме» темасы буенча сүз байлыгын активлаштыру, тәрбияче соравына җавап бирү осталыгын, игътибарын, күзәтүчәнлеген, сенсор тою сәләтен үстерү;<br>3) матурлыкны күрә һәм соклана белү хисләре, чыршы уенчыкларына карата сакчыл караш тәрбияләү. | “Туган телдә сөйләшәбез “Ф. В. Хәзрәтова, З. Г. Шәрәфетдинова, И. Җ. Хәбибуллина 62 б. |
| Декабрь 4 нче атна | “Чыршы бизибез” | 1) балаларның Яңа ел бәйрәме турындагы күзаллауларын баетуны дәвам итү;<br>2) балаларның «Яңа ел бәйрәме» темасы буенча сүзлеген активлаштыру, тәрбияче соравына җавап бирү осталыгын, игътибарын, күзәтүчәнлеген, сенсор тою сәләтен үстерү<br>3) чыршы уенчыкларына карата сакчыл караш тәрбияләү. | “Туган телдә сөйләшәбез “Ф. В. Хәзрәтова, З. Г. Шәрәфетдинова, И. Җ. Хәбибуллина 62 б. |
| Гыйнвар 2 нче атна | “Алсу урамга җыена” | 1) Балаларның кышкы киемнәр турындагы белемнәренә төгәллек кертү; урамга чыкканда киенү эзлеклелеген һәм киемнәрне истә калдыру, тәрбияче сорауларына җавап бирергә күнектерү;<br>2) балаларның игътибарын, хәтерен, фикерләвен, сүз байлыгын үстерү;<br>3) башкаларга ярдәм итү теләге булдыру, киемнәргә сак караш тәрбияләү. | “Туган телдә сөйләшәбез “Ф. В. Хәзрәтова, З. Г.Шәрәфетдинова, И. Җ. Хәбибуллина 69 б. |
| Гыйнвар 3 нче атна | “Күгәрченнәр, чыпчыклар — безнең нәни кошчыклар” | 1) Мәйданчык тагы җимлеккә килгән кошларны күзәтү, исемнәрен әйтү; гөр-гөр, чырык-чырык, кар-кар аваз ияртемнәрен ачык итеп әйтерг ә күнектерү; томшык, сикерә, гөрлиләр, җим, чүплиләр, чырыл дый, җитез, өлгер сүзләре хисабына сүзлекне баету; 2) балаларның игътибарын, күзәтүчәнлеген, сорауларга җавап бирү осталыгын үстерү; 3) кошлар турында кайгырту, аларга ярдәм итү теләге тәрбияләү. | “Туган телдә сөйләшәбез “Ф. В. Хәзрәтова, З. Г.Шәрәфетдинова, И. Җ. Хәбибуллина 71 б |

| | | | |
|---|---|---|---|
| Гыйнвар 4 нче атна | “Чанада шуабыз” | 1) Балаларны рәсемне карарга, анын эчтәлеген анларга, эчтәлеге буенча сорауларга җавап бирергә өйрәтүне дәвам итү;<br>2) диалогик сөйләмнәрен, күзәтүчәнлекләрен, күрсәтмәобразлы фикерләүләрен үстерү;<br>3) кышнын матурлыгын күрә белергә өйрәтү, кыш көне нинди күнелле уеннар уйнарга булуын ачыклау | “Туган телдә сөйләшәбез “Ф. В. Хәзрәтова, З. Г.Шәрәфетдинова, И. Җ. Хәбибуллина 44 б |
| Февраль 1 нче атна | “Кунак каршылыйбыз” | 1) Савыт-сабаның аерым предметлары, аларның кулланылышы турында белемнәренә төгәллек кертү; тәрбияче белән бергә кыска хикәя төзергә өйрәнүне дәвам итү; әңгәмәгә тарту; 2) балаларның игътибарын, аңга алуларын үстерү; тәрбияче биргән сорауны ишетү, аңлау һәм аңлаешлы итеп җавап бирүләренә ирешү; үз исемен дөрес итеп әйтә белергә өйрәтү; 3) балаларда сөйләм этикетына нигез салу (исәнләшү, танышу, саубуллашу); өлкәннәргә бу лышу теләге уяту; савытсабага сакчыл караш тәрбияләү. | “Туган телдә сөйләшәбез “Ф. В. Хәзрәтова, З. Г.Шәрәфетдинова, И. Җ. Хәбибуллина 34 б |
| Февраль 2 нче атна | “Йорт җиһазлары” | 1 Баларны йорт җиһазлары белән таныштыру: өстәл, урындык, диван,шкаф. 2 Йор җиһазлары сүрәтләнгән рәсемнәргә карап зшләүне формалаштыру. 3 Рәсемне карарга  һәм предметларның өлешләренә игътибар итәргә, катлаулы булмаган өй җиһазлары төзергә өйрәтү (Урындык, өстәл) 4 Дус тату бердәм эшләүне тәрбияләү. | Интернет чыганакларыннан |
| Февраль 3 нче атна | “Ватанны саклаучылар көне” | 1) балаларны Ватанны саклаучылар көне белән таныштыру;<br>2) балаларның игътибарын, аңга алуларын; диалогик, монологик сөйләмнәрен үстерү;<br>3) балаларда Туган илгә мәхәббәт, малайларда көчле, кыю булырга омтылыш тәрбияләү. | “Туган телдә сөйләшәбез “Ф. В. Хәзрәтова, З. Г.Шәрәфетдинова, И. Җ. Хәбибуллина 49 б. |
| Февраль 4 нче атна | “Бүлмә гөлләре” | 1) балаларның гади сорауларга җавап бирү осталыгын камилләштерү, бүлмә гөлләренең өлешләрен өйрәтү, аларның сыйфат билгеләрен белдерә торган сүзләр хисабына сүзлекне баету;<br>2) гөлләр белән кызыксынуларын үстерү; 3) гөлләрне караганда, өлкәннәргә ярдәм итү теләге тәрбияләү. | “Туган телдә сөйләшәбез “Ф. В. Хәзрәтова, З.Г.Шәрәфетдинова, И. Җ. Хәбибуллина 129 б |

| | | | |
|---|---|---|---|
| Март<br>1 нче атна | “Безнең әниләр” | 1) Балаларны әниләр һөнәренә кагылышлы сюжетлы кечкенә рәсемнәрнең эчтәлеген аңларга өйрәтү, эш-хәрәкәтне белдерә торган сүзләр хисабына балаларның сүз байлыгын киңәйтү;<br>2) балаларның кабул итү сәләтен, куелган сорау-ларга кыска җөмлә белән җавап бирү осталыгын,игътибарын үстерү;<br>3) төрле һөнәр кешеләренә һәм әниләр хезмәтенәкарата кызыксыну, хөрмәт тәрбияләү. | “Туган телдә сөйләшәбез “Ф. В. Хәзрәтова, З.Г.Шәрәфетдинова, И. Җ. Хәбибуллина 80 б |
| Март<br>2 нче атна | “Яз,яз килә!” | 1) Балаларга язгы күренешләр (кар эри, тамчы тама, кояш җылыта, сулар җыела) турында башлангыч белемнәр бирү, сүз байлыгын киңәйтү һәм активлаштыру; 2) балаларның күзәтүчәнлеген, игътибарын үстерү; 3) табигатьтәге язгы күренешләр белән кызыксындыру | “Туган телдә сөйләшәбез “Ф. В. Хәзрәтова, З.Г.Шәрәфетдинова, И. Җ. Хәбибуллина 83 б |
| Март<br>3 нче атна | “Җәнлекләр урманда яши” | 1) җәнлекләр турында балаларның белемнәрен киңәйтү һәм ны-гыту, җәнлекләрне таный һәм исемнәрен атый белергә өйрәтү;<br>2) балаларның диалогик сөйләмен активлаштыру, фикерләвен, мөстәкыйльлеген үстерү;<br>3) җәнлекләр белән кызыксындыру. | “Туган телдә сөйләшәбез “Ф. В. Хәзрәтова, З.Г.Шәрәфетдинова, И. Җ. Хәбибуллина 85 б |
| Март<br>4 нче атна | “Сыерчыклар, карлыгачлар килде”. | 1) балаларны үзләренә таныш кошларны рәсемнән танырга һәм исемнәрен әйтергә өйрәтү; балаларның сүз байлыгын арттыру, сүзлеккә *сыерчык, сыерчык оясы, карлыгач* сүзләрен кертү;<br>2) игътибарны, күзәтүчәнлекне, тәрбияче белән аралашу, сорауларга җавап бирү осталыгын үстерү;<br>3) кошлар һәм табигать белән кызыксынуларына ирешү, кошларга карата мәрхәмәтлелек, кайгыртучанлык тәрбияләү | “Туган телдә сөйләшәбез “Ф. В. Хәзрәтова, З.Г.Шәрәфетдинова, И. Җ. Хәбибуллина 86 б |
| Апрель<br>1 нче атна | “Юл йөрү кагыйдәләре.” | 1. Балаларны юл йөрү кагыйдәләре белән таныштыру.2). Урамның тротуар белән машиналар йөри торган өлешен аерырга өйрәтү. 3. Светофорның яшел, кызыл, сары сигналлары турында аңлату. 4. Урамда үз-үзеңне дөрес тоту кагыйдәләрен кабатлау, ныгыту. | Интернет чыганакларыннан |
| Апрель<br>2 нче атна | “Галләмгә сәяхәт” | 1 Балаларны космонавт профециясе белән, планеталар: Кояш, Ай, Җир | Интернет чыганакларыннан |

| | | | |
|---|---|---|---|
| | | белән таныштыру, аңлату.<br>2 Фикер йөртү, фантазияны,хәтерне, куз аллауны үстерү.<br>3 Тирә юньгә карата сак караш, кызыксынучанлык үстерү. | “Сабыйга. Ру” |
| Апрель<br>3 нче атна | “Әкият иленә сәяхәт” | 1 Әкияткә карата кызыксыну уяту, балаларга әкиятне тыңларга, эчтәлеген аңлый белергә өйрәтү.<br>2. Сөйләмнең диалог формасын үзләштерү, сөйләм телен үстерү, сүз байлыгын арттыру, кул чуклары мускуллары хәрәкәтен үстерү.<br>3. Балаларга дус мөнәсәбәт, ярдәмләшәсе килү теләген тәрбияләү. | “Сабыйга. Ру”<br>Интернет чыганакларыннан |
| Апрель<br>4 нче атна | “Чиста булыйк” | Шәхси гигиена предметларын дөрес куллану күнекмәләрен ныгыту.<br>Үз сәламәтлегең турында кайгыртучанлык һәм чисталыкка омтылыш тәрбияләү.<br>Игътибарлылык һәм хәтер сәлатен үстерү. | Интернет чыганакларыннан |
| Апрель<br>5 нче атна | “Аквариумдагы балыклар” | Баларны аквариумдагы балыклар белән таныштыр балыкларны күзәтергә, аларнынң тән төзелешләрен карау, өйрәнү.<br>2 Баларга балыклар артыннан игътибар белән карырга аларны ашатырга кирәклеге турында белемнәрен артыру<br>3 Сорауларга җавп бирүне сөйләм телен, хәтерне үстерү.<br>4 Табигатькә карата кызыксыну тәрбияләү. | Интернет чыганакларыннан |
| Май<br>1 нче атна | “Бөҗәкләр” | 1) Балаларны бөҗәкләр белән, аларның исемнәре белән таныштыру;2)аларга карата сакчыл караш тәрбияләү;3) хәтерне игътибарлыкны үстерү. | Интернет чыганакларыннан |
| Май<br>2 нче атна | “Тузганак чәчәге” | 1) Балаларны үсемлекләр белән таныштыруны дәвам итү; тузганак чәчәген күрсәтү, аны танырга, исемен әйтергә, төзелеше (чәчәге, сабагы, яфраклары) буенча аера белергә өйрәтү; сүз байлыгын үстерү; тузганак, чәчәк, сабак сүзләрен сөйләмдә активлаштыру; 2) балаларның сенсор тою һәм кабул итү сәләтен, игътибарын, күзә түчәнлеген үстерү; 3) табигать белән турыдан-туры аралашудан шатлык хисләре уяту, үсемлекләргә сакчыл караш тәрбияләү. | “Туган телдә сөйләшәбез “Ф. В. Хәзрәтова, З.Г.Шәрәфетдинова, И. Җ. Хәбибуллина 89 б |

| | | | |
|---|---|---|---|
| Май<br>3 нче атна | “Мин җәөне яратам” | 1) табигатьтәге җәйге үзгәрешләр турындагы күзаллауларын киңәйтү, билгеле бер ситуациягә туры килгән фигыльләрне сөйләмдә куллануларын активлаштыру, «бер», «күп» төшенчәләрен ныгыту; 2) балаларның игътибарын, диалогик сөйләмен, уңай хискичерешләрен, аңга алуларын үстерү; 3) табигатькә сакчыл караш тәрбияләү | Туган телдә сөйләшәбез “Ф. В. Хәзрәтова, З.Г.Шәрәфетдинова, И. Җ. Хәбибуллина 103 б |
| Май<br>4 нче атна | “Ком һәм аның үзенчәлекләре” | Бурычлар: 1) балаларны комны тикшерергә (комны учка алырга, йомарларга һәм сибәргә), төсе буенча аның дымлылыгын билгеләргә өйрәтү; 2) коры, дымлы, юеш, сибелүчән, сибелә, әвәләү сүзләре хисабына балаларның сүз байлыгын киңәйтү, игътибарны, сенсор тою сәләтен үстерү; 3) ком белән уйнарга кызыксындыру | “Туган телдә сөйләшәбез “Ф. В. Хәзрәтова, З.Г.Шәрәфетдинова, И. Җ. Хәбибуллина 89 б |

**Комплекслы – тематик план**

**Аралашу(сөйләм үстерү)**

| Вакыты | Тема | Бурычлар | Әдәбият |
|---|---|---|---|
| Сентябрь<br>1нче атна | Кем нәрсә эшли? | 1 Балаларның сөйләмен үстерергә ярдәм итү, рәсемнәр карарга, анда сурәтләнгән предметларны һәм аларның сыйфатларын атарга, рәсемдә сурәтләнгән уенчыкны, предметны өстәлдә табып, исемен, гамәлен атый белергә өйрәтү; 2) игътибарны, кабул итү сәләтен үстерү; 3) уенчыкларга карата сакчыл мөнәсәбәт тәрбияләү | “Туган телдә сөйләшәбез “Ф. В. Хәзрәтова, З. Г. Шәрәфетдинова, И. Җ. Хәбибуллина 96 б. |
| Сентябрь<br>2нче атна | Предметларның төсләрен тану һәм атау. «Паровоз» дидактик күнегүе | 1) Төсләрне белдерә торган сыйфатлар хисабына балаларның сөйләмен баету (кызыл, яшел, сары), [ү] авазының дөрес әйтелешенә ирешү; 2) балаларның игътибарын, кабул итү сәләтен, төсләрне тану һәм атау осталыгын үстерү; 3) эшчәнлеккә карата кызыксыну, күмәк эшчәнлек белән шөгыль ләнү теләге тәрбияләү. | “Туган телдә сөйләшәбез “Ф. В. Хәзрәтова, З. Г. Шәрәфетдинова, И. Җ. Хәбибуллина 97 б. |
| Сентябрь<br>3нче атна | "Сары, кызыл яфраклар” | 1) Балаларны көз, кыш ел фасылларының характерлы билгеләре белән таныштыру; бер ел вакыты икенчесен алмаштыруы турында мәгълүмат бирү; көзге яфраклар турындагы белемнәрен (яфракларның төсләре үзгәрә, алар коелалар) киңәйтү. Авазлар әйтелешен ныгыту; 2) балаларның игътибарын, аңга | “Туган телдә сөйләшәбез “Ф. В. Хәзрәтова, З. Г. Шәрәфетдинова, И. Җ. Хәбибуллина 31 б. |

| | | | |
|---|---|---|---|
| | | алуларын, хәтерен, бәйләнешле сөйләмен үстерү; 3) күзге табигатьнең матурлыгын күрә белергә өйрәтү; балаларда чиста, пөхтә эшләү теләге тәрбияләү. | |
| Сентябрь 4нче атна | “Яшелчәләр” | 1) яшелчәләрне белдерә торган исемнәр (бәрәңге ,помидор, суган ,кишер) һәм аларның үзлекләрен белдерә торган сүзләр хисабына балаларның сүзлеген баету, яшелчәләрне танырга өйрәт ү, сөйләмнең грамматик төзелешен камилләштерү; 2) балаларның сенсор тою сәләтен үстерү; 3) яшелчәләр, аларның файдасы турында мәгълүмат бирү | “Туган телдә сөйләшәбез “Ф. В. Хәзрәтова, З. Г. Шәрәфетдинова, И. Җ. Хәбибуллина 101 б. |
| Октябрь 1 нче атна | Бакчада алмалар өлгерде | 1) Балаларның көз, табигатьтәге көзге үзгәрешләр, җиләкҗимешләр (алма, аның билгеләре) турында күзаллауларын баету нигезендә сүзлек запасын киңәйтү һәм активлаштыру, тиңдәш кисәкләр кергән җөмләләр төзергә өйрәтүне дәвам итү; 2) балаларның игътибарын, аңга алуларын, хәтерен, сенсорик күнекмәләрен, артикуляция аппаратын үстерү; 3) күмәк эшләүгә тарту, сорауларга җавап бирү теләге тәрбияләү. | “Туган телдә сөйләшәбез “Ф. В. Хәзрәтова, З. Г. Шәрәфетдинова, И. Җ. Хәбибуллина 70 б. |
| Октябрь 2 нче атна | “Уенчыклар бездә кунакта” | 1 Төсне, зурлыкны, эш-гамәлне белдерә торган сүзләр (зур, кечкенә, яшел, кызыл, утырт, эчерт, керт) хисабына балаларның сүз байлыгын арттыру, аралашу осталыгы формалаштыру; 2) балаларның предметны исеме, төсе, зурлыгы буенча табу осталыгын, сенсор тою сәләтен, игътибарын, хәтерен үстерү; 3) уенчыкларга карата сакчыл мөнәсәбәт тәрбияләү. | “Туган телдә сөйләшәбез “Ф. В. Хәзрәтова, З. Г. Шәрәфетдинова, И. Җ. Хәбибуллина 98б. |
| Октябрь 3 нче атна | “Пирамидалар” | 1) Балаларны предметларның зурлыгын, төсен билгеләргә өйрәтү; төсне (кызыл, яшел, сары, зәңгәр), зурлыкны (зур, кечкенә, зуррак, кечкенәрәк, иң зурысы, иң кечкенәсе) белдерә торган сүзләр ярдәмендә сүз байлыгын арттыру; аваз иярттемнәрен ачык әйтүдә күнектерү;<br>2) игътибарны, кабул итүне, сенсор тою сәләтен үстерү; 3) түземлелек, дидактик уеннар белән кызыксыну тәрбияләү. | “Туган телдә сөйләшәбез “Ф. В. Хәзрәтова, З. Г. Шәрәфетдинова, И. Җ. Хәбибуллина 99 б. |

| | | | |
|---|---|---|---|
| Октябрь 4 нче атна | “Бу мин” | 1) Организм һәм аның өлешләре турында балаларда күзаллау формалаштыру, үзләрен бербөтен итеп кабул итәргә өйрәтү, гәүдә өлешләре турында белемнәрен ачыклау һәм ныгыту; 2) гәүдә өлешләренең атамалары (баш, күзләр, колаклар, борын, авыз, тешләр, чәч, куллар, аяклар) хисабына балаларның сүзлеген активлаштыру; 3) үзеңне, гәүдә өлешләреңне ярату, игътибарлы булу, культурагигиена күнекмәләрен үтәү теләге тудыру. | “Туган телдә сөйләшәбез “Ф. В. Хәзрәтова, З. Г. Шәрәфетдинова, И. Җ. Хәбибуллина 54 б. |
| Октябрь 5 нче атна | «Бу өйдә кем яши?» дидактик уены | 1) Төркемгә йөрүче балаларның исемнәрен истә калды рырга ярдәм итү, фигыльләрне хәзерге һәм киләчәк заманда кулл а на белергә өйрәтү, сорауны белдерә торган сүзләрне кулланырга күнектерү; 2) игътибарны, кабул итү сәләтен, диалогик сөйләмне үстерү; 3) бер-береңә карата игътибарлылык тәр бияләү. | “Туган телдә сөйләшәбез “Ф. В. Хәзрәтова, З. Г. Шәрәфетдинова, И. Җ. Хәбибуллина 107 б. |
| Ноябрь 1 нче атна | Машина һәм самолет | 1) Балаларны уенчыкларның өлешләрен, төсен, формасын аерырга һәм атарга өйрәтү; исемнәрне сыйфатлар белән яраклаштыру күнекмәләре формалаштыруны дәвам итү; [у] сузык авазын әйтүдә күнектерү, сүзлекне активлаштыру; уенчыклар белән таныштыруны дәвам итү; 2) балаларның нинди? кайда? нәрсә ташый? сорауларына төзек гади җөмләләр белән җавап бирү осталыгын, игътибарын үстерү; 3) шофёр, очучы һөнәрләренә хөрмәт тәрбияләү. | “ Туган телдә сөйләшәбез “Ф. В. Хәзрәтова, З. Г. Шәрәфетдинова Хәбибуллина 123 б. |
| Ноябрь 2 нче атна | “Бозау, бәрән, колын, кәҗә бәтие, сез кайда?” | 1) Балаларның йорт хайваннары турындагы белемнәрен киңәйтү; бозау ,бәрән, колын ,кәҗә бәтие сүзләре хисабына сүзлекне 135 баету һәм активлаштыру, тәрбияче күрсәтмәләрен үтәү осталыгы формалаштыру; 2) игътибарны, хәтерне үстерү; 3) башкаларга ярдәм итү теләге, тыңлаучанлык, хайваннарга карата кайгыртучанлык тәрбияләү. | “Туган телдә сөйләшәбез “Ф. В. Хәзрәтова, З. Г. Шәрәфетдинова, И. Җ. Хәбибуллина 134 б. |

| | | | |
|---|---|---|---|
| Ноябрь 3 нче атна | «Чуар тавык» әкиятен уку | 1) Балаларны халык авыз иҗаты әсәрләре белән таныштыруны дәвам итү, әкиятне тыңлау теләге тудыру; чуар, күкәй, алтын, гади, тычкан кебек сүзләр хисабына балаларның сүзлеген баету; 2) тәрбияче башлаган җөмләне дәвам итү осталыгын, хәтерне, игътибарны, кабул итү сәләтен үстерү; 3) әкият персонажларына карата кызыксыну тәрбияләү. | “Туган телдә сөйләшәбез “Ф. В. Хәзрәтова, З. Г. Шәрәфетдинова, И. Җ. Хәбибуллина 128 б. |
| Ноябрь 4 нче атна | “Матрешкалар” | 1) Уенчыкның исемен (матрёшка) дөрес әйтергә, төсендә һәм зурлыгында булган аерманы күрә белергә күнект ерү; зур, кечкенә, сарафан, яулык сүзләре исәбенә сүзлекне активлаштыру; 2) балаларның игътибарын, күзәтүчәнлеген, сорауларга җавап бирү осталыгын үстерү; 3) балаларда халык уенчыкларына кызыксыну тәрб ияләү. | “Туган телдә сөйләшәбез “Ф. В. Хәзрәтова, З. Г. Шәрәфетдинова, И. Җ. Хәбибуллина 128 б. |
| Декабрь 1 нче атна | “Алсу урамга жыена” | 1) балаларның кышкы киемнәр турындагы белемнәренә төгәллек кертү; урамга чыкканда киенү эзлеклелеген һәм киемнәрне истә калдыру, тәрбияче сорауларына җавап бирергә күнектерү;<br>2) балаларның игътибарын, хәтерен, фикерләвен, сүз байлыгын үстерү;<br>3) башкаларга ярдәм итү теләге булдыру, киемнәргә сак караш тәрбияләү. | “Туган телдә сөйләшәбез “Ф. В. Хәзрәтова, З. Г. Шәрәфетдинова, И. Җ. Хәбибуллина 69 б. |
| Декабрь 2 нче атна | “Ләйлә суыктан курыкмый” | 1) рәсемне карарга, рәсемдә ясалган предметларны танырга, исемнәрен дөрес әйтергә өйрәтү; предметларны, эш-хәрәкәтне, төсне белдерә торган сүзләр ярдәмендә сүзлекне активлаштыру, рәсем эчтә леге буенча сорауларга җавап бирергә күнектерү; 2) кабул итү сәләтен, игътибарны, хәтерне үстерү; 3) сюжетлы рәсемнәр карарга теләк уяту. | “Туган телдә сөйләшәбез “Ф. В. Хәзрәтова, З. Г.Шәрәфетдинова, И. Җ. Хәбибуллина 70 б. |
| Декабрь 3 нче атна | “Куян чыршы янында” | 1) сөйләмдә бәйлек сүзләрне (эчендә, артында, астында, өстендә) кулланырга, кайда? кая? сорауларына җавап бирергә, тәрбияче һәм иптәшләре белән ирекле аралашырга өйрәтүне дәвам итү; тавыш көчен дөрес куллану осталыгы формалаштыру; 2) игътибарны үстерү, тәрбияче күрсәтмәләрен үтәүдә күнектерү; 3) нәфис сүз белән кызыксыну тәрбияләү. | “Туган телдә сөйләшәбез “Ф. В. Хәзрәтова, З. Г.Шәрәфетдинова, И. Җ. Хәбибуллина 113 б |

| | | | |
|---|---|---|---|
| Декабрь<br>4 нче атна | “Купшы чыршы” | 1) сузык һәм тартык авазларны, аваз ияртемнәрен ачык әйтергә, төбендә сүзен сөйләмдә кулланырга өйрәтү; сыйфатларны дөрес кулланырга күнектерү; 2) сорауларга җавап бирү осталыгын, игътибарны, күзәтүчәнлекне үстерү; 3) табигатькә соклану хисләре тәрбияләә | “Туган телдә сөйләшәбез “Ф. В. Хәзрәтова, З. Г.Шәрәфетдинова, И. Җ. Хәбибуллина 112 б |
| Гыйнвар<br>2 нче атна | «Шундый ук предметны тап» дидактик уены | 1) үз фикерләрен грамматик яктан дөрес итеп ике-өч сүздән торган гади җөмләләр белән белдерергә өйрәтү, гомумил әштерү күнекмәсе булдыру, предметларны чынбарлыкта һәм рәс ем дә таныргa өйрәтү, предметларның билгеләнешен ачыклау, сүз байлыгын арттыру һәм активлаштыру;<br>2) тәрбияче сорауларына гади җөмлә белән тулы җавап бирү осталыгын, игътибарны, сенсор тою сәләтен үстерү;<br>3) гигиена күнекмәләре тәрбияләү | “Туган телдә сөйләшәбез “Ф. В. Хәзрәтова, З. Г.Шәрәфетдинова, И. Җ. Хәбибуллина 121б |
| Гыйнвар<br>3 нче атна | “Кошлар” | 1) балаларны аваз ияртемнәрен дөрес һәм ачык итеп әйтер гә, алардан фигыльләр (гөр — гөрли ,чырык — чыркылдый, кар — каркылдый) ясарга өйрәтү; гомумиләштерүче сүзләрне (та вык ,әтәч, каз — йорт кошлары) кулланырга күнектерү; кош исемнәрен, гәүдә өлешләрен, хәрәкәтләрне белдерүче сүзләр хисабына сүз байлыгын активлаштыру, балаларны кошлар белән таныштыруны дәвам итү; 2) балаларның игътибарын, хәтерен, сөйләмен үстерү; 3) кошларга карата кызыксыну, кайгыртучанлык тәрбияләү. | “Туган телдә сөйләшәбез “Ф. В. Хәзрәтова, З. Г.Шәрәфетдинова, И. Җ. Хәбибуллина 118б |
| Гыйнвар<br>4нче атна | “Юл чистартабыз” | 1) Балаларның кыш һәм кыш көне башкарылаторган хезмәт күнекмәләре турындагы белемнә-рен формалаштыру, көрәк белән эшләргә өйрәтү,ишегалдын җыештыручы хезмәте белән таныштыру, балаларның сүзлеген активлаш тыру, аерым<br>сүзтезмәләр не (*зур көрәк, кечкенә көрәк, ак кар,күп кар, әз кар*) ачык итеп әйтүдә күнектерү;*2*) хезмәт күнекмәләрен, кеше хәрәкәтләрен ими-<br>тацияләү осталыгын үстерү; 3) зурларга ярдәм итү һәм гади хезмәт хәрәкәтләре үтәү теләге тәрбияләү. | “Туган телдә сөйләшәбез “Ф. В. Хәзрәтова, З. Г.Шәрәфетдинова, И. Җ. Хәбибуллина 120б |

| | | | |
|---|---|---|---|
| Февраль<br>1 нче атна | “Савыт –саба” | 1.Балаларның савыт – саба турындагы белемнәрен үстерү.<br>2. Сүз байлыгын арттыру.<br>3. Сүрәтләнгән рәсемнәргә предметларны дөрес сайлап алырга өйрәтү<br>4. Ярдәм итергә тырышу, мәрхәмәтлелек тәрбияләү. | “Сабыйга. Ру” |
| Февраль<br>2 нче атна | “Алсуның яңа өе” | 1) Балаларны йорт җиһазлары белән таныштыру, бил геләнешләре буенча гомумиләштерергә өйрәтү; бирелгән сорауны аңлау һәм җавап бирүләренә ирешү; 2) җиһаз предметларының атамасын һәм билгеләнешен, аларның нинди материалдан эшләнгәнен ачыклауларына ирешү; артында, янында, өстендә кебек сүзләр хисабына сүзлек байлыгын үстерү; 3) йорт җиһазларына карата сакчыл караш тәрбияләү. | “Туган телдә сөйләшәбез “Ф. В. Хәзрәтова, З. Г.Шәрәфетдинова, И. Җ. Хәбибуллина 79 б |
| Февраль<br>3 нче атна | “Безнең әтиләр” | 1) Балаларны әтиләр һөнәренә кагылышлы сюжетлы кечкенә рәсемнәрне карарга, аларның эчтәлеген аңларга өйрәтү; эш-гамәлләрне белдерә торган сүзләр хисабына балаларның сүз байлыгын үстерү; 2) балаларның игътибарын, хәтерен, фикерләвен, куелган сорауларга кыска җөмлә белән җавап бирү осталыгын, сүз байлыгын үстерү; 3) төрле һөнәр кешеләренә һәм әтиләр хезмәтенә карата кызыксыну уяту. | “Туган телдә сөйләшәбез “Ф. В. Хәзрәтова, З. Г.Шәрәфетдинова, И. Җ. Хәбибуллина 74 б |
| Февраль<br>4 нче атна | “Яран гөл” | 1) Балаларны бүлмә гөле — яран гөл һәм аның өлешләре белән таныштыру; сабак, яфрак, чәчәк сүзләре хисабына сүзлекләрен активлаштыру;<br>2) балаларның зурлар белән аралашуына, аларны аңлауларына ирешү; күзәтүчәнлекләрен, игътибарларын үстерү; 3) бүлмә гөлләренә карата кызыксынучанлык, аларны карау теләге тәрбияләү. | “Туган телдә сөйләшәбез “Ф. В. Хәзрәтова, З. Г.Шәрәфетдинова, И. Җ. Хәбибуллина 126 б |
| Март<br>1 нче атна | «Алсу бәйрәмгә җыена» дидактик уены | 1) өс киемнәре, аларның төсе һәм материалы белән таныштыруны дәвам итү, сүзлекне активлаштыру: ефәк, ак, чәчәкле кебек яңа сүзләр кертү; 2) балаларның игътибарын, хәтерен, фикерләвен, сорауларны ишетә һәм аларга бер сүз яки кыска җөмлә белән җавап бирү осталыгын үстерү; 3) курчаклар белән уйнарга теләк уяту, уенчыкларга сакчыл караш тәрбияләү. | “Туган телдә сөйләшәбез “Ф. В. Хәзрәтова, З. Г.Шәрәфетдинова, И. Җ. Хәбибуллина 77 б |

| | | | |
|---|---|---|---|
| Март<br>2 нче атна | “Язгы урманда” | 1) *Кайда? нинди?* сорауларына җавап бирергә өйрәтү; *өстә, агач төбендә* сүзләрен куллану хисабына сөйләмнең грамматик төзелешен камилләштерү; аваз ияртемнәрен дөрес әйтүдә күнек-терү; [ш] авазының дөрес әйтелешен ныгыту, ел фасылларына бәйле табигатьтәге үзгәрешләр турында белемнәрен формалашты-<br>руны дәвам итү; 2) балаларның игътибарын, күзәтүчәнлеген үстерү;<br>3) табигать объектларына сакчыл караш тәрбияләү. | “Туган телдә сөйләшәбез “Ф. В. Хәзрәтова, З. Г.Шәрәфетдинова, И. Җ. Хәбибуллина 139 б |
| Март<br>3 нче атна | “Йомры икмәк белән урманга сәяхәт” | 1) балаларның кыргый һәм йорт хайваннары турындагы белемнәрен ныгыту, 2) балаларның сенсор яки сәләтләрен, предметларны тану, аларның төсләрен аеру мөмкинлекләрен ныгыту,<br>3) балаларның игътибарын, күзәтүчәнлеген үстерү;<br>4) табигать объектларына сакчыл караш тәрбияләү. | Интернетресурс |
| Март<br>4 нче атна | “Сыерчыклар килде” | 1) балаларның  карлыгачлар, сыерчыклар  турындагы белемнәрен ныгыту,<br>2) кошларны төс кыяфәтләре буенча танырга өйрәтү.<br>3) үз ягыннын табигатенә мәхәббәт уяту.<br>балаларның игътибарын, күзәтүчәнлеген үстерү;<br>4)  табигать объектларына сакчыл караш тәрбияләү. | Интернетресурс |
